пометой *occ.* [= occasionally] ‘иногда; изредка’.

2) указатели лексико-грамматических характеристик частей речи:

- *числа* имен существительных. Например: **listener**. An ear: low and boxers’: from ca. 1805. Boxiana, II, 1818. (*Gen. in pl.*). Здесь помета множественного числа (***in pl.*** [= plural] ‘во множественном числе’) заключена в скобки и располагается в самом конце словарной статьи. В следующем примере помета единственного числа (***in sing.*** [= singular] ‘во множественном числе’) располагается в скобках непосредственно после вокабулы: **sparklers** (rare in sing.). Bright eyes: mid-C.18-20: S.E. until 1850, then coll.; in C.20, s. In pugilistic s. of ca. 1805-60, any sort of eye, as in *Boxiana,* III, 1821, ‘One of his *sparklers* got a little damaged.’;

- *переходности–непереходности* глаголов (пометы: ***v.t.*** [= verb transitive] ‘переходный глагол’; ***v.i.*** [= verb intransitive] ‘непереходный глагол’). Например: **straight-set,** v.t. To defeat in the minimum number of sets (i.e. in *straight sets)*: lawn-tennis coll.: 1935; **chant,** v.i., to swear: sporting: 1886—ca. 1914. Если глагол может быть одновременно переходным и непереходным, то обе пометы подаются вместе после дефиниции. Например: **nob,** v. To punch on the head, v.t. and v.i.: boxing: 1812; **feed,** v. In football, to back, v.i. and t.: from ca. 1880;

- *залоговости* глаголов (пометы: ***in active*** ‘в действительном залоге’; ***in passive*** ‘в страдательном залоге’). Например: **back-marked, be.** To have one’s athletic handicap reduced: late C. 19-20 coll., ob. Rare in active voice; **claret,** v. (Usually in passive.) To draw blood from, to cause to be covered with blood. ‘Purcell’s mug was clareted’ (Boxiana, II, 1818). Как следует из обоих примеров, в словарной статье помета залоговости глаголов не имеет устойчивого месторасположения: она может помещаться либо перед дефиницией, либо после нее.

Наконец, в редких случаях возможно совместное использование указателей непереходности (помета ***v.i.***) и залоговости (помета ***in passive***). Например: **puncture.** 2. *V.i. and in passive*, (of cycle or rider) to get a puncture: coll.: from ca. 1893. Ex the tyre’s being punctured. OED.

Таким образом, вокабулы со спортивным значением в словаре Э. Партриджа регулярно снабжаются пометами, раскрывающими их грамматическую характеристику. Недостаток словаря видится 1) в нерегулярном использовании грамматических помет, 2) в их неустойчивом, подвижном расположении в словарной статье. В целом, данный словарь предлагает пользователям достаточный набор помет для определения грамматических свойств спортивной сленговой единицы.

### Литература


1. Рябичкина Г.В. Теоретические аспекты разработки социолексикографического инструментария // Альманах современной науки и образования. – Тамбов: Грамота, 2008. – №8 (15): в 2-х ч. Ч. II. – С. 167-169.
2. Рябичкина Г.В. Типы помет в «Словаре сленга и нестандартного английского языка» Э. Партриджа (социолексикографический анализ) // Вестник ТГУ. – Вып. 11 (67), 2008. – С. 220-225.
3. Partridge, E. A Dictionary of Slang and Unconventional English / Edited by Paul Beale. 8th ed. / E. Partridge, NY: Macmillan Publishing Co., 1984, XXIX, 1400 p.


**УДК 82.512.145**

**А.М. Закирзянов**

*Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, г. Казань, Россия*

# ПЬЕСА И.ЮЗЕЕВА “МОЙ БЕЛЫЙ КАЛФАК” НА СЦЕНЕ ТЕАТРА Г.КАМАЛА

***Аннотация.*** *В статье анализируется спектакль театра им. Г.Камала по пьесе И.Юзеева “Мой белый калфак”. Особое внимание уделяется идейно-эстетическому содержанию пьесы и способам, приемам его раскрытия через игру актеров и художественное оформление спектакля.*

***Ключевые слова:*** *Юзеев, пьеса, идея, спектакль, интерпретация, режиссер, художник, артист.*

**A.M. Zakirzyanov**

*G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art, Tatarstan Academy of Sciences, Kazan, Russia*

# "THE TIME WHEN THE WHITE KALFAK WAS FOUND" (ILDAR YUZEEV`S PLAY ON THE KAMAL THEATRE STAGE)

***Abstract.*** *The performance of the Galiaskar Kamal Tatar Academic Theatre "The time when the white kalfak was found" written by Ildar Yuzeev is analyzed in the article. The special attention is paid to the ideological esthetical content of the play, the means and methods of its development with the help of acting and the performance's decorations.*

***Key words:*** *Yuzeev, a play, an idea, a performance, an interpretation, a producer, an artist, an actor*

# АК КАЛФАКНЫҢ ТАБЫЛГАН ЧАГЫ (И.ЮЗЕЕВ ПЬЕСАСЫ Г. КАМАЛ ТЕАТРЫ СӘХНӘСЕНДӘ)

Илдар Юзеев исеме киң җәмәгатьчелеккә яхшы таныш. Ул XX гасырның икенче яртысы татар әдәбиятын лирик шигырь-поэмалары, заманның җитди мәсьәләләре урын алган пьесалары белән баетып, романтизм юнәлешенең үсеш-үзгәрешенә гаять зур өлеш кертте [3, б. 156]. Шигырь-җырлары бүген дә радио-телевидениедән яңгырый, пьесалары сәхнәләрдән төшми уйнала. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры И. Юзеевнең "Ак калфагым төшердем кулдан..." (1990) әсәре буенча яңа спектакль тәкъдим итте. Җәмгыятьтә кискен үзгәртеп корулар барган чорда язылган әсәр 27 елдан соң да актуальме? Спектакль нинди яңалык алып килә?

Киң катлам җәмәгатьчелеккә яшьлек һәм мәхәббәт җырчысы булып танылган, яшәешне романтик принциплардан чагылдыруга өстенлек биргән әдип, әлеге пьесада реализм алымнары аша татар җәмгыятендәге гаять җитди мәсьәләләрне укучы һәм тамашачы хөкеменә чыгара. Фәрит Бикчәнтәев җитәкчелегендәге коллектив театрда яңа аваз булып яңгыраган спектакль иҗат иткән. Сәхнәдә вакыйгалар Нью-Йорк һәм Казан арасындагы телевизион күпер рәвешендә бара. Художник уңышлы вариантны тапкан: сәхнә икегә бүленеп, чиге сәхнәнең арткы өлешен буйга кисеп үткән кино лентасына килеп тоташа, ә ул исә каршы якларны чагылдырган зур экраннарны үзара бәйләп тора. Сәхнә алдында телевизорны хәтерләткән кечкенә экраннарда уен чагыла. Шул рәвешле, вакыйгаларны телевизордан караган халәт тудырылса да, татар милләтенең үткәненә, бүгенгесенә һәм киләчәгенә бәйле куелган сораулар, тамашачыны сәхнә тормышы белән яшәргә мәҗбүр итә.

Спектакльдәге вакыйгалар безне 80 елларның икенче яртысына алып китә. Америка телестудиясенә төрле сәбәпләр аркасында туган ил-җирләреннән китәргә мәҗбүр булган, шулай ук чит илдә туып-үскән милләттәшләр җыелган. Аларга гадилек, гадәтилек, һәрнәрсәне ачык һәм аңлаешлы итеп әйтү һәм шуны ук каршы яктан ишетергә теләү хас [1, б. 119]. Казан ягыннан алып баручы Клара Измайлова (арт. Рушания Юкачева) бер-бер артлы катнашучылар белән таныштыра. Әнә шунда инде чор рухы калкып чыга. 70 ел буе коммунистик идеология сөреме белән агуланган кешеләр һич тә бертөрле түгел. Өлкән буын вәкилләре Исмай Акчурин (арт. Әзһәр Шакиров) белән Шәмсия Ишмуллинада (арт. Рузия Мотыйгуллина) чит илләрне, шунда яшәүчеләрне дошман күрү, курку, шикләнү ачык чагылса, Регина Хәбиби (арт. Венера Шакирова) кебек яшьрәк буын вәкиленең инде акны карадан аеручы, үз фикерен әйтергә һәм якларга әзер икәнлеге күренә. Мәшһүр рәссам булып танылган Исмай Акчурин күңелендә үзгәрешләр башланса да, ул куркуын яшерми, әледән әле "Дөнья – куласа!" дип кабатлый. Алып баручы Клара Измайлованың "Дошманнарча провакацион сораулар бирелә калса, сак булыгыз..." дигән сүзләре шул чорның иҗтимагый мохитен ачык чагылдыра. Әмма икенче мизгелдә әлеге күренешләрнең бүгенгебезгә туры килүен аңлыйсың.

Спектакльне татар халкының бүгенгесе, аннан да бигрәк киләчәге өчен борчылу, сызлану иңләп үтә. Әйе, "татар халкы үзенең чисталык-пөхтәлеге, сабырлыгы, хезмәт яратуы белән танылу алган" [2, б. 24]. Милләтебез ярдәмчеллеге, читләр белән янәшә гомер итә алуы, өлкәннәргә хөрмәте белән дә башка халыкларның ихтирамын яулады. Шуңа да пьеса авторы һәм аның карашларын заман рухында чагылдырырга омтылган режиссер татар халкының бүгенгесен һәм киләчәген, беренче чиратта, милли сыйфатларның, традицияләрнең, гореф-гадәтләрнең сакланышы белән бәйләп карый. Күп тапкырлар әйтелгәнчә, гүзәл милли бәйрәмебез Сабантуй ул гади күңел ачу, ял итү генә түгел, Сабантуй ул – халкыбызның күңел хәрлеге, гасырлардан килүче рухи кыйммәтләре чагылышы, үзара дуслык, бердәмлек билгесе, халыкчан осталык һәм кыюлык, матурлык һәм батырлык, хыял һәм омтылыш чагылышы. Әлеге бәйрәмдәге уен-ярышларда халыкның иң матур сыйфатлары ачыла. Шуның берсе – ат чабышында иң арттан килгән, хәлсезләнгән атның муенына ак сөлге салу күренеше. Америка ягыннан алып баручы Сафия Нурхан (арт. Люция Хәмитова) үткән елны Татарстанга килеп, авылларның берсендә көянтә-чиләк белән су ташу ярышында катнаша. Ә инде ялгыш егылып калгач, Клара аңа ярдәмгә ашыга. Режиссер, гаять үтемле итеп,

әлеге ике күренеш арасындагы мәгънәви уртаклыкны күрсәтә. Сафия Нурхан аны болай аңлата: “Әгәр халкыбыз артта калган атларның муенына ак сөлге бәйләү хисен югалтса, милләт буларак яшәүдән туктаячак”.

Телевизион күпердә катнашучы якларны нәкъ менә милли билгеләрнең, яшәү рәвешенең, гореф-гадәтләрнең бозылуы, кайберләренең инде югалуы өчен борчылу хисе берләштерә. Әнә бер авылда колга-баганага ак сөлге урынына хәмер элеп куйганнар, көрәш батырына бүләккә тәкә урынына дуңгыз биргәннәр. Әлеге күренештә арттыру урын алса да, авторның тирәнтен борчылуы, тамашачы игътибарын бу мәсьәләләргә юнәлтүе ачык чагыла. Милли идеяне ачуда Иванов (арт. Наил Дунаев) зур роль уйный. Әлеге рольдә артистның таланты бөтен барлыгында ачыла. Наил Дунаев герое керәшен милли киемендә булуы, халык җырларын оста, мәгънәле итеп башкаруы, гади-гадәтилеге белән генә түгел, бәлки милли йөзен, күңелендә көрәш рухын саклавы белән җәлеп итә. Спектакльне сызлану фәлсәфәсе иңләп үтә. Ул, беренче чиратта туган тел язмышы белән бәйле. Кызганыч ки, Финляндиядә яшәүче аз санлы татарлар телләрен, гадәт-йолаларын саклаган вакытта, туган илендә яшәүче милләттәшләребезнең байтагы ана телендә аралашмый. Моның сәбәпләре турында уйланганда, милли үзаңның йомшаклыгы да искәртелә.

Спектакльдә без чын мәгънәсендә фаҗигале язмышлар белән очрашабыз. Үз илендә танылып килүче яшь рәссам 35 яшьлек Тайфур (арт. Искәндәр Хәйруллин) яшәп килгән тәртипләр, идеологик карашлар белән каршылыкка керә. Бу яшь кешенең халкыбызга хас матур сыйфатларның, милли йөзебезнең югалуы турындагы каты, кискен сүзләре артында Регинага булган мәхәббәте, туган илен оныта алмавы ачыла. Чит илгә киткәч бер генә рәсем-картина да ясый алмавы күңелендәге каршылыкны, рухи кризисын күрсәтә. Яшь егет бу халәтеннән чыга алмый һәм үзен үзе үтерә. Аның үлеме спектакльдә егетне шундый хәлгә куйган совет системасына нәфрәт булып яңгырый, тамашачы исә бүгенгебезгә гаять аваздаш булуын аңлап, тоеп утыра. Исмай Акчурин язмышы да тетрәндергеч. Әзһәр Шакиров герое яшьтән ук “дошман баласы” дигән хурлыклы исем күтәреп йөргән. Укырга керү өчен әтисеннән баш тартырга мәҗбүр булган егет күңелендә курку хисе тирән урнашкан. Ул идеология рупорына әйләнә, Тайфур Кормаш кебек талантларны яклаудан баш тарта. Җәмгыятьтә хәзер барган үзгәрешләргә дә бик сак килә, һәрвакыт икеләнә, бутала, ачык кына җавап бирми. Шулай да Исмай Саттарович күңелендә дә үзгәрешләр башланган. Пьесада сурәтләнгән фаҗигале язмышларның иң үкенечлесе, мөгаен, Жак (арт. Илдус Әхмәтҗанов) белән Шәмсия әбидер. Жак-Габделхак сугышта әсирлек газабын кичерә. Аннан котылгач, француз партизан отрядында сугышып йөрсә дә, туган иленә кайтмый. Америкага күчеп килеп, гомере буе туган илен, телен, газиз әнкәсен, җыр-моңнарын сагынып яши. Бу вакыт эчендә бердәнбер куанычы итеп әнисенен ак калфагын саклый. Улын танырга да теләмәгән ана, үзенең истәлеге булган ак калфак турында ишеткәч, күз алдында үзгәрә.

Драматург тоталитар системаның, торгынлык еллары идеологиясенең кешелексез якларын ача. Туган илләрен ташлап китәргә мәҗбүр булучыларны гаепләргә түгел, бәлки аңларга, мәрхәмәтлелек күрсәтергә чакыра. Режиссер һәм артистлар уены әлеге вакыт арасын үтеп чыгып, вакыйгаларны бүгенге көн белән бәйләп кабул итәргә, уйланырга, бәхәсләшергә, икеләнергә мөмкинлек бирә. Пьесаның заманчалыгы һәм шул ук вакытта спектакльнең тамашачы белән диалог кора алу үзенчәлеге әнә шунда. Әсәр исеме дә халык җырыннан алынган – “Ак калфагым төшердем кулдан...” Спектакльдә халык җыры лейтмотив буларак яңгыраш ала: татарның МОҢ символы дип бәяләнгән Илһам Шакиров кына түгел, бәлки америкада туып-үскән Зөбәйдә Прайс та (арт. Алинә Мөдәррисова) җырлый аны. Ә инде ахырда телевизион күпердә катнашучыларның бергәләп әлеге җырны башкаруы киләчәккә өмет хисе уятып, күңелләргә бердәмлек идеясен сала. Гомумән, спектакльдә татар милләте язмышы белән тыгыз бәйләнештә куелган җитди мәсьәләләр тамашачыны кузгата, битарафлыктан чыгара, уйланырга, бәхәсләшергә этәрә. Шуңа да әлеге спектакль Камал театры артистларының, режиссер Фәрит Бикчәнтәевнең җитди уңышы булып тора.

**Әдәбият**


1. Әхмәдуллин А.Г. Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе. – Казан: Мәгариф, 2007. –223 б.
2. Закирҗанов Ә.М. Заман белән бергә // Заман белән бергә: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2004. – Б. 16-45.
3. Игъламов Р.М. Хакыйкатьне эзләү юлыннан // Казан утлары. – 1993. – № 1. – Б. 156-161.